КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 22 ноябрь г.Казань № 1068

2019 елгы уңышның азык-төлек арышы ашлыгын Татарстан Республикасының азык-төлек резервына реализацияләүгә бәйле булган чыгымнарның бер өлешен каплау өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Азык-төлек арышы ашлыгының резерв запасын булдыру максатларында, «Татарстан Республикасының азык-төлек куркынычсызлыгы турында» 2017 елның 13 июлендәге ТРЗ-53 номерлы Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2013 – 2022 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 8 апрель, 235 нче карары белән расланган «2013 – 2022 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2019 елгы уңышның азык-төлек арышы ашлыгын Татарстан Республикасының азык-төлек резервына реализацияләүгә бәйле булган чыгымнарның бер өлешен каплау өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен расларга.
2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 22 ноябрь, 1068 нче
карары белән расланды

2019 елгы уңышның азык-төлек арышы ашлыгын
Татарстан Республикасының азык-төлек резервына реализацияләүгә бәйле булган
чыгымнарның бер өлешен каплау өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә
Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү
тәртибе

1. Бу Тәртип авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш), шулай ук эшчәнлекләрен календарь елдан кимрәк гамәлгә ашырган, 2019 елда 2019 елгы уңышның азык-төлек арышы ашлыгын (1 – 3 класслы) Татарстан Республикасының азык-төлек резервына реализацияләгән авыл хуҗалыгы оешмаларына (алга таба – субсидияләр, алучылар) авыл хуҗалыгы культураларын җитештерү һәм реализацияләү чыгымнарының бер өлешен каплауга (өстәмә кыйммәткә салымны исәпкә алмыйча (алга таба – өстәмә кыйммәткә салым) субсидияләр бирү механизмын билгели.

2. Субсидияләр бирү тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм бу Тәртипнең 1 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына (алга таба – Министрлык) бюджет акчасын алучы буларак билгеләнгән тәртиптә ирештерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.

3. Субсидия алучыларны сайлап алу критерийлары булып түбәндәгеләр тора:

алучыларның агымдагы финанс елында авыл хуҗалыгы культураларын чәчү мәйданнары булуы;

авыл хуҗалыгы культураларын җитештерү һәм реализацияләү эшчәнлеген гамәлгә ашыру;

2019 елгы уңышның азык-төлек арышы ашлыгын (1 – 3 класслы) (алга таба – бөртек) Татарстан Республикасының азык-төлек резервына реализацияләү.

4. Субсидия аны алучы түбәндәге таләпләргә туры килгән очракта бирелә:

а) субсидия бирү турында карар планлаштырыла торган кабул итү көненә кадәр 15 эш көненнән дә артмаган вакытка:

законнар белән билгеләнгән тәртиптә теркәлгән һәм җитештерү эшчәнлеген Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашырган;

алучы – бетерү процессында булмаган юридик зат, аңа карата банкротлык процедурасы башланмаган, субсидия алучының эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән каралган тәртиптә туктатылмаган, ә субсидия алучы – индивидуаль эшмәкәр буларак эшчәнлеген туктатмаган;

чит ил юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталларында теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы раслый торган дәүләтләр һәм

территорияләр исемлегенә кертелгән салым салуның ташламалы салым режимы һәм (яки) финанс операцияләре үткәргәндә мондый юридик затларга мөнәсәбәттә мәгълүматны ачу яки бирү күздә тотылмаган дәүләт яки территория (офшор зоналар) булган чит ил юридик затлары өлеше гомумән алганда 50 проценттан артып киткән россия юридик заты булмаган;

бу Тәртипнең 1 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алмаган;

субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча үз вакытында түләнмәгән бурычлары һәм Татарстан Республикасы бюджеты каршында үз вакытында түләнмәгән башка бурычлары булмаган;

Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәләре булмаган;

б) бу Тәртип белән күздә тотылган максатлар өчен субсидияләр элегрәк алучыга бирелмәгән.

5. Субсидия күләме алучылар тарафыннан Татарстан Республикасының азык-төлек резервына реализацияләнгән 1 тонна ашлык өчен 1 500,0 сум (өстәмә кыйммәткә салымнан тыш) исәбеннән чыгып билгеләнә.

6. Бу Тәртип нигезендә субсидияләр алу өчен алучылар Министрлыкка түбәндәге документларны кертә:

Министрлык боерыгы белән расланган форма буенча үзенең түләү реквизитлары һәм почта адресы күрсәтелгән субсидияләр бирү турындагы гаризаны, шул исәптән анда түбәндәгеләр турында мәгълүмат бирелә:

субсидия алучы закон белән билгеләнгән тәртиптә теркәлү һәм житештерү эшчәнлеген Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыру;

субсидия алучы – юридик зат бетерү процессында булмау, аңа карата банкротлык процедурасы башланмау, субсидия алучының эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылган тәртиптә туктатылмау, ә субсидия алучы – индивидуаль эшмәкәр эшчәнлеген индивидуаль эшмәкәр буларак туктатмау;

алучы чит ил юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталларында теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы раслый торган дәүләтләр һәм территорияләр исемлегенә кертелгән салым салуның ташламалы салым режимы һәм (яки) финанс операцияләре үткәргәндә мондый юридик затларга мөнәсәбәттә мәгълүматны ачу яки бирү күздә тотылмаган дәүләт яки территория (офшор зоналар) булган чит ил юридик затлары өлеше гомумән алганда 50 проценттан артып киткән Россия юридик заты булмау;

субсидия алучы бу Тәртипнең 1 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә акча алмау;

алучының субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча үз вакытында түләнмәгән бурычлары һәм Татарстан

Республикасы бюджеты каршында үз вакытында түләнмәгән башка бурычлары булмау;

алучының Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәләре булмау;

Министрлык тарафыннан расланган форма буенча бирелергә тиешле субсидияләр турында исәп-хисап белешмә кәгазен;

Татарстан Республикасының азык-төлек резервына ашлык китерү шартнамәсе күчермәсен;

Татарстан Республикасының азык-төлек резервына ашлык китерү счет-фактурасы һәм (яки) йөкнамә күчермәсен;

алучының агымдагы финанс елында булган авыл хуҗалыгы культураларын чәчү мәйданнары (гектарда) турындагы мәгълүматны.

Кертелгән документларның күчермәләре алучылар тарафыннан раслана.

Субсидия алучылар үз инициативасы белән салым органының салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча бурычлары булмавын раслый торган белешмә кәгазен кертергә хокуклы. Әлеге документ субсидия алучы тарафыннан үз инициативасы белән кертелмәгән очракта, Министрлык аны салым органыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.

7. Министрлык:

субсидия алу турындагы гаризаны «Татарстан Республикасының агросәнәгать комплексы» мәгълүмат системасында кергән көнне теркәүгә ала;

гариза теркәлгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 15 көн эчендә кертелгән документларны бу Тәртипнең 6 нчы пунктына туры килү-килмәвен карап тикшерә һәм субсидия бирү турында яки субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

Субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

документларны тулы комплектта кертмәү яки алар бу Тәртип таләпләренә туры килмәү;

субсидия алучы тарафыннан бирелгән мәгълүмат дөрес булмау;

бюджет йөкләмәләре лимиты булмау.

Бюджет йөкләмәләре лимиты җитәрлек булмаган очракта, субсидияләр гаризалар бирү чираты тәртибендә бирелә.

Субсидияләр бирүдән баш тартылган очракта, Министрлык алучыга бу пунктның өченче абзацында күрсәтелгән вакыт чыкканнан соң эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә алучыга бу турыда хәбәрнамә җибәрә.

8. Татарстан Республикасының азык-төлек резервын кимендә 1 тонна ашлыкка тулыландыру субсидияләр бирүнең нәтиҗәсе була.

9. Министрлык Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче булып тора һәм субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә үзенең Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган шәхси счетыннан алучыларның кредит оешмаларында ачылган исәп-хисап счетына акча күчерүне гамәлгә ашыра.

Алучылар тарафыннан Министрлыкка тиешле субсидияләр турында тапшырылган исәп-хисап белешмә кәгазе субсидияләрне күчерү өчен нигез булып тора.

10. Алучылар субсидияләр бирелгән елдан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр бу Тәртипкә теркәлгән кушымтада бирелгән форма буенча субсидияләр бирү нәтиҗәсенә ирешү турындагы хисапны Министрлыкка кертә.

11. Бирелгән субсидияләр, бу Тәртип белән билгеләнгән аларны бирү тәртибен һәм шартларын бозу фактлары ачыкланган очракта, шулай ук Министрлык һәм вәкаләтле дәүләт финанс тикшерүе органы тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр фактлары буенча Министрлыкның тиешле таләбен алган көннән 60 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә бюджет законнары нигезендә кире кайтарылырга тиеш.

12. Бу Тәртипнең 11 нче пунктында күрсәтелгән акчаны Татарстан Республикасы бюджеты керемено ирекле рәвештә кире кайтарудан баш тартылган очракта, алар Министрлык тарафыннан законнар нигезендә мәҗбүри рәвештә түләттерелергә тиеш.

13. Закон нигезендә Министрлык һәм дәүләт финанс тикшерүе органнары алучыларның субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыра.

14. Министрлыкка алучылар тарафыннан кертелә торган документларның дөреслеге өчен җаваплылык тиешле вазыйфаи затларга һәм җитәкчеләргә йөкләнә.

15. Бюджет акчасыннан файдалануны тикшерүдә тоту Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2019 елгы уңышның азык-төлек арышы ашлыгын Татарстан Республикасының азык-төлек резервына реализацияләүгә бәйле булган чыгымнарның бер өлешен каплау өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә кушымта

Форма

20__ елның ________________ енә(ына)
субсидияләр бирү нәтиҗәсенә ирешү турында
ХИСАП

Оешма – субсидия алучы исеме: ________________________________________

| Т/с | Күрсәткеч исеме | Гомумроссия үлчәү берәмлекләре классификаторы буенча үлчәү берәмлеге | | Хисап датасы хәленә ирешелгән күрсәткеч мәгънәсе |
|---|---|---|---|---|
| | | исеме | коды | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1. | Татарстан Республикасының азык-төлек резервын 2019 елгы уңышның азык-төлек арышы ашлыгы белән тулыландыру күләме | тонна | 168 | |

Оешма – субсидия алучының
җитәкчесе________________ _____________________
(имзасы) (Ф.И.Ат.ис.)
М.У.

Баш бухгалтер ________________ _____________________
(имзасы) (Ф.И.Ат.ис.)

20__ елның «____» ______________

______________________________